


Салават күпере
журналына кушымта
Сыбызгы
№3

Аяз Гыйләҗев

Кадерле дускай!

Татарстанның халык язучысы, Г.Тукай, Г.Исхакый һәм Россиянең М.Горький исемендәге бүләкләре иясе Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев халкыбызга гыйбрәтле романнары, пьесалары, мавыктыргыч повестьлары белән танылды. Ул балалар өчен дә матур-матур хикәяләр яза, күңелләргә гүзәллек, игелеклелек орлыклары чәчә.



© "Сыбызгы", 2001 ел



Матур

Сыбызгы

Искәндәр авыру булгач, Разияның әнисе:

– Ишек алдында гына йөр, аларга керәм дия күрмә. Менә терелсен, аннары бергәләп уйнарсыз, – диде.

Разия авызын турсайтып урамга чыгып китте. Кыш килгәндә һавада эре-эре кар бөртекләре бөтерелгәндә ничек инде берүзең генә уйнап булсын? Аларның күршесендә Галия исемле бер кыз бар барын. Тик Разия аны яратмый. Бер нәрсә булды исә, Галия сугышырга гына тора. Менә бүген дә Разияның урамга чыгуы булды, Галия:

– Син безнең тауга килмә! – дип кычкырды.

Разия аңа эндәшеп тә тормады. Андый гына тау Искәндәрләр өе янында да бар.

Искәндәр күренмәсме дип, Разия аларның тәрәзәсе янына барды. Җиң очына кунган бик матур, сырлы-сырлы кар бөртеген күрсәтергә уйлаган иде ул. Әмма суык Искәндәрләр тәрәзәсен кар бөртеге төсле бизәкләр белән каплап ук куйган икән. Разия кулларын тәрәзәгә сузып караса да, буе җитмәде. Әтисе аны юкка гына үскән кызым дип йөри икән. Бер дә үсмәгән. Менә Равил абыйсы үскән ичмасам. Җәй көне тәрәзәнең иң өстеннән Разияга чыпчык балалары алып күрсәтте ул. Буе җитмәгән иде, үрмәләп менде. Тукта әле, Разия да үрмәләп менә алмас микән?









Бик күрәсе килә иде аның Искәндәрне. Чирләгәч ниндиерәк булды икән? Әбисе, авырып, яңагын чуар яулык белән бәйләп куйгач, Разияга бик кызык булган иде. Искәндәр дә шундый кызык микән?

Кечкенә кыз, кулындагы агач көрәген ташлап, почмактагы бүрәнә башларына ябышып өскә менә башлады. Бүрәнә башларына кар сырылган икән, кулы шуып китеп, әллә ничә мәртәбә җиргә егылды. Күп тырышкач, өскә үрмәли башлады. Түбәнгә караган иде: башы әйләнеп китте. Чытырдатып күзләрен йомды, куллары-аяклары белән стенага ябышты. Төшәргә дә, менәргә дә куркыныч иде. Күз төпләреннән яшь бөртекләре килеп чыкты. Аннары Разия акрын гына шыңшый башлады. Түзмәде, авызын зур ачып, елап җибәрде. Тавышка әллә каян Галия килеп чыкты. Ул сыңар аягында сикергәләп, Разия тирәсендә бөтерелергә кереште.

– Төшә алмый, төшә алмый! Гарьлек, әллә-лә! – дип черелдәде ул. Өйалды ягында Искәндәрнең әбисе күренде. Ул, камырлы кулларын алъяпкычына сөртә-сөртә, Разия янына йөгерә иде. Аны күргәч, Галия тишек бияләеннән чыгып торган кап-кара бармагы белән сипкелле борынын күтәреп, мәзәк ясады һәм урамга чыгып йөгерде.

Әби елауданмы, туңуданмы калтырый башлаган Разияны җиргә төшереп бастырды.

– Әй, балакаем, балакаем? Кая болай менмәкче идең син?

– Тәрәзәгә.

– Нигә?

– Искәндәрне карарга.

– И, кызым, кызым! – дип Разияның аркасын какты әби. – Озакламас, терелер. Шул чагында керерсең. Ә хәзер бар, кайтып җылын, битләрең туңып беткән.

– Мин туңмадым, – диде Разия иреннәрен түгәрәкләндереп.

Шулай да кайтып китәргә туры килде. Кайтса, әнисе яңа гына томаланган мичкә зур калай белән өчпочмаклар салып маташа. Разия кулларын чәбәкләде:





– Әни, мин икене ашыйм, яме! – дип кычкырды ул.

– Аш-су янына өсне чишенеп керергә кирәк, кызым.

Бераздан тамак төбен кытыклап өчпочмакларның исе чыкты. Разия әнисен йөдәтеп бетерде:

– Әни, берне генә алып бир инде, – дип сорады ул.

Җөй тегеп утырган әнисе сәгатькә караштырып кына тора иде. Менә ул эссе бөркеп торган мич авызыннан сары майда кетердәп пешкән, алсу өсле өчпочмакларны чыгарды.

Берне ашады Разия, икенчегә тотынган иде, туйды. Чәй дә йотып карады, үтмәде. Ул чәй тәлинкәсендәге зур гына өчпочмак кисәгенә карап иреннәрен ялап куйды. Шул вакытта аның башына бер уй килде.

Ул әнисе күрмәгәндә генә өчпочмак кисәген өстәлдән бер читкә алып китте. Газета бите ертып алып аны бик әйбәтләп кенә төрде һәм киенеп урамга чыкты. Әнисе:

– Озак йөрмә, хәзер әтиең кайта, – дип кычкырып калды.

Разия Искәндәрне өчпочмак белән сыйларга уйлаган иде. Искәндәрләр ишеге төбенә җиткәч, тукталып калды: тәмле кисәкне Искәндәргә ничек бирергә? Шулай аптырап торганда, аның күзе болдырда уйнап йөргән песи баласы Матурга төште. Разияның абыйсы сугышта йөк ташучы этләр була дип сөйләгән иде ич. Матур да шундый эшне эшли ала бит!

Матур тоттырмыйча озак кына интектерде. Тотам гына дигәндә, үзе белән уйныйлар дип белеп, аркасына ятты, аунады һәм чабып китте.

Азаплана торгач Разия Матурны эләктереп алды. Ул озак уйлап тормады, бияләен тагып куйган җепне өзеп алды да өчпочмакны Матурның муенына бәйләп куйды. Бик саклык белән генә болдырга менде, өйалды ишеген ачты. Як-ягына каранып, Матурның колагына:

– Искәндәрнең үзенә генә бир, берәү дә күрмәсен, – дип пышылдады. Матурны өйалдына кертеп җибәргәч, үзе түбәнгә төште. Агач көрәген табып алып тау өйде, тау башына ике агач утыртып куйды. Кайсы якка борылса да, күзе Искәндәрләрнең өйалды ишегендә булды. Матур күренми дә күренми. Кызыйның түземе бетте. Ул яңадан болдырга менде һәм сакланып кына ишекне ачты. Башта ул берни дә күрмәде. Караңгыга күзе ияләшкәч, Разия иң элек өй ишеген һәм ишек янында тыныч кына өчпочмак ашап утырган Матурны күрде.

Разия елаган тавышка өйдән Искәндәрнең әбисе килеп чыкты.

– Тагын ни булды, кызым? Ник елыйсың?

– Минә Матур...

– Нәрсә Матур?

– Өчпочмакны ашаган, бөтенесен ашап бетергән, бер почмагын да калдырмаган...

– Нинди өчпочмакны?

Разия сөйләп биргәч, әби көлеп җибәрде. Разияның иптәшенә булган якынлыгы аның күңелен нечкәртте. Ул, күтәреп алып, Разияны өйгә алып керде. Чишендереп өстәл янына утыртты.

– Үзем дә бүген өчпочмак пешергән идем. Искәндәр ашады да йокыга китте, – диде ул. Өстәлгә булары чыгып торган ике өчпочмак китереп куйды.

– Үзеңне дә сыйлыйм әле, кызым, аша, – диде.

Разия ике өчпочмакны ашады да бетерде. Искәндәрнең әбисе пешергән өчпочмаклар тагын да тәмлерәк кебек тоелдылар аңа. Ни өчен икән?

Кече якта Искәндәр йоклый. Тупсада җепмуенса таккан Матур утыра.

– Һе, явыз! – дигән булды әби аңа карап һәм кечкенә тәлинкәгә сөт салып бирде.





Алсу, Илдус һәм сандугач

Көннәрнең берендә, кызының йокы капчыгына әйләнеп баруын күргән әнисе Алсуны үзе дә йокыдан торган вакытында ук уятты. Салкын су белән бит-күзләрен юдырды, лапастан вак утын керттерде, сыерны көтүгә куарга кушты, үзе шуннан соң гына фермага йөгерде. Алсу, гадәтенчә, әле суынып та өлгермәгән мендәренә башын куйды, күзләрен йомды. Әмма йокы килмәде. Алай борылды кыз, болай тәгәрәде, юк кына бит. Йоклап булмый. Алсу йоклап яткан энесенә көнләшеп карады. Аннары түзмәде, тегенең касыгына төртте:

– Илдус!

Малай йокыда килеш касыгын кашып куйды.

– Илдус!

– Әйем лә, уятма әле!


– Тор! Әкият сөйлим.

Малай дәшмәде.

Алсу, турсаеп, бөгәрләнеп ятты. Ә йокы килмәде. Сызылып кына чыккан кояш килде аның күз алдына, балаларына суалчан эзләп очкан сыерчыклар килде, ат саклаудан кайтучы малайларның су буен яңгыратып сызгырып үтү-

ләре килде. Әмма йокы килмәде...

Кыз юрганын тибеп төшерде, аннары үзе торды. Кече якка чыкты. Өстәлдәге сөтне кабып карады: тәмсез! Нишләргә белмичә арлыбирле йөргәч, Алсу бакча як тәрәзәне ачып җибәрде. Аларның өе янындагы бакчада өздереп-өздереп бер кош сайрый иде. Кыз сискәнеп китте. Сандугач ич бу! Моннан өч ел элек тә аларның бакчаларына сандугач оялаган иде. Әтисе еш кына Алсуны бакчага алып чыгып аның сайравын тыңлата иде.



«Бәхетле, тырыш кеше бакчасына гына оялый торган асыл кош ул», дия иде. Быел да алар бакчасына сандугач килгән! Тизрәк Илдусны уятырга кирәк!

Алсу Илдусны йолыккалап уятты һәм тәрәзә янына алып килде:

– Сандугач килгән, сандугач! Безнең бакчада оя ясаган!

Малай кояш нурларыннан сукырайган күзләрен челт-мелт йомып торды. Ул берни дә аңламый да, ишетми дә иде.

– Сандугач инде, би-ик! Чыпчык чырылдый!

– Нинди чыпчык булсын! Әнә, әнә тагын сайрый!

Илдус тәрәзәгә башын тыкты һәм, йокысы ачылып киттеме шунда, кош сайравын ишетте:

– Апа, сандугач шушы буламы инде? – дип сорады ул.

– Шушы, шушы! Мин иң элек күрдем, сандугач минеке була! – дип сикергәләде Алсу.

– Әһә, – диде Илдус. – Синеке булмый торсын әле. Сандугач миңа була. Әнә миңа карап тора. Миңа гына карап сайрый!

Алсу сикерүеннән туктады, аның зәңгәр күзләренә шигәю чыкты:

– Кайда, кайда, күрсәт әле!

– Кайманда катык ашый! Шуны дә күрмисеңме, әнә сирень ботагында!

Алсу да, Илдус үзе дә, бик текәлеп карасалар да, берни күрмәделәр. Алсу энесенең хәйләсен сизеп алды.

– Сирень агачына кунмый да әле ул сандугач, – диде кыз.





– Кем сиңа сирень агачында ди? Әнә ич, сәрвигә кунып миңа карап тора!



Юк, бу юлы да күрмәделәр алар сандугачны. Сәрви агачларын әллә нинди чүп үләннәр, корыган ботаклар күмеп киткән иде. Анда-санда гына калкып маташкан ботакларның кайсысына кунып сайрагандыр сандугач, Алсу белән Илдус аны эзләп таба алмадылар. Бераздан кош тынды.



Кузгалак җыйганда да, гөрле-качышлы уйнаганда да, мәктәп бакчасында кишер, суганнарга су сипкәндә дә Алсу белән Илдусның телендә сандугач кына булды. Кич белән алар әниләренә дә мактанып өлгерделәр:

– Безнең бакчага сандугач оялаган. Шундый шәп сайрый!

– Әйбәт булган, балалар, – диде әниләре. – Иртә-кич сайрап торыр ичмасам. Тик бакчаны бер дә карамыйсыз әле. Чүп басып китә бит. Безнең вакыт җитми, сез тыңламыйсыз.

«Һәй, – диде Алсу эченнән генә, – агачны чүп басып бетерәме?»



Кич җитте. Тәрәзәләрне киң ачып, сандугач сайравын көттеләр. Тик кош сайрамады. Әрем сабакларына, әрекмән яфракларына текәлеп юкка гына күз талдырдылар, сандугач күренмәде. Куак арасыннан мырлый-мырлый соры песи генә килеп чыкты.



– Әһә, – диде Илдус, – шушы куркыткан аны!

Песине тотып чоланга алып керделәр һәм әниләренең кер элә торган бавы белән бәйләп куйдылар.

Сәрви ботаклары арасында чыпчыклар чыркылдашты.



– Шушы карак чыпчыклар булганга килмәгәндер ул, – диде Алсу.

Таш ата-ата чыпчыкларны Галәвиләр тыкрыгына кадәр кудылар. Кичке җил дәү әрекмән яфракларын тирбәтте, агачтан-агачка күчә-күчә төн килде, сандугач килмәде.

Килмәгән килмәде инде, икәве дә йокларга яттылар.

Җәйге төн кыска ла ул! Бер саплам җеп кебек кенә. Теге якта шәфәкъ уты сүнеп тә бетми, бу якта утлы керфекләрен сирпеп таң ярала.

Алсуның күзләренә кояш нуры төште. Ул сикереп торып ишек алдына чыкты. Әнисе сыер сава. Амбар өстенә үк менеп баскан чуар әтәч, бугазын киереп, кычкырыпмы-кычкыра.

– Әни, сандугач сайрамадымы?

– Ишетелмәде, кызым. Иртә торгансың, йокла әле...

Тик Алсуны йокы алмады. Ул учларын яңагына терәп сандугачны көтте, Тәнзиләләр, Фәйрүзәләр дә бүген сандугач сайравын тыңларга монда килергә булдылар... Инде нишләргә?

Алсу ул көнне мәктәп бакчасына да бармады, Фәйрүзәләрдән дә качып йөрде. Икенче көнне дә, өченче көнне дә сандугач тавыш бирмәде. Алсу да, Илдус та ул курыкмасын дип бакчага эз басмадылар, сандугач ашасын дип җим сипteләр. Тавык-чебеш кереп йөрмәсен дип коймадагы тишек-тошыкларны каплап бетерделәр. Тик сандугач барыбер килмәде. Чүп арасыннан баш калкыта алган сирень ботакларына тәлгәш-тәлгәш чәчәкләр эленде. Чыпчыклар чыркылдады. Сыерчык балалары оя тишегеннән сары томшыкларын сузып чи-чи дип









кычкыра башладылар. Фәйрүзәләр, Тәнзиләләр мактанчык дип Алсудан көлделәр, Фәритләр, Мансурлар ялганчы дип Илдусның күзен дә ачырмадылар. Нишләсеннәр, сандугач аларны бер котыртты да китеп барды.



Бер көнне, Алсу белән Илдус сандугачны онытып бетереп барганда әниләре эштән иртәрәк кайтты.

– Ирендегез, ирендегез, балалар. Алыгыз көрәк, тотыгыз тырма, бакчаны рәткә китерик әле, – диде ул.

– Мин эшләмим, мәктәптә дә тырыш, монда да эшлә, – дип иреннәрен бөрештерде Алсу.

– Әһә, – диде Илдус, – минем түтәлләр синекеннән озынрак та әле. Мин дә эшләмим.

– Бакчада эш барыгызга да җитәрлек, – диде әниләре.

Күпме карулашып була? Энеле-сеңелле икәүләшеп бакчага керделәр. Бакчада яланаяк йөрерлек тә түгел, кычыткан басып бетергән. Башта аларны чабып койма буена өйделәр. Сары, озын тамырларын казып чыгарып чокырга күмделәр. Сукыр кычытканнарны, эт эчәгеләрен, әрем-билчәннәрне йолкып ыргыттылар. Менә чүп арасыннан сиреньнәрнең яшь шытымнары килеп чыкты, баш калкытып азапланган сәрвиләр иркенләп канат җәйделәр. Өскәрәк үрләгән сирень ботакларында күз явын алырлык матур тәлгәшләр асылынып калды.



– Чәчәкләре ачылырга тора ич боларның, – диде Алсу.

– Әһә, – дигән булды Илдус, – бүген генә күрдеңме шуны?






– Менә хәзер рәхәтләнеп үсәрләр инде, – диде әниләре, маңгай тирен сөртеп.

Бакча киңәеп, матурланып китте. Илдус белән Алсу, бик арсалар да, куышып уйнап та алдылар.



Кай арада кич булды да караңгы төште. Алсу белән Илдус йокларга яттылар.

Чү! Алсу төш күрәме, әллә чыннан да уянганмы? Тәрәзәдән нур бөркелә, ачык ишектән иртәнге салкынча һава агылып керә һәм баш очында гына өздереп-өздереп бер кош сайрый. Сайрый, сызгырып җибәрә. Сандугач! Алсу атылып барып Илдусны уятты:

– Илдус! Тор! Сандугач килгән!



Малай әллә ни арада гына торып өлгерде дә тәрәзә төбенә түше белән яткан апасының итәгеннән тартты:

– Карама, тагын куркытасың!

Ләкин Илдус үзе дә тәрәзәдән күзен ала алмады. Иң башта ул бакчаны танымый торды. Тәлгәш-тәлгәш сырган сирень чәчәкләре төн эчендә тулышып ачылып беткәннәр. Төнлә яңгыр сибәләгән, ахры, алар меңнәрчә су бөртекләренә бизәлеп акрын гына чайкалып утыралар. Төртке-төртке сәрви чәчәкләрендә бал кортлары выжылдый. Һәм яфраклар иң мул, чәчәкләр иң куе урында очына-очына сандугач сайрый...





Сандугач шул килүеннән китмәде. Шунда оя ясады. Бик яратты ул Илдусларның бакчасын. Алсу белән Илдус та ул бакчаны бик ярattылар. Аларга бик күп сөенечле минутлар, рәхәт иртәләр алып килде ул сандугач...









Рәссам **Алла АЙСИНА**

Баш мөхәррир **Зиннур ХӨСНИЯР**
Баш мөхәррир урынбасары Вакыйф НУРИЕВ
Бүлек мөхәррире Ләбиб ЛЕРОН
Бизәлеш мөхәррире Фәрит МУЛЛАХМӘТ
Компьютер дизайны Мөнирә КУЗИЕВА
Исәп-хисап бүлеге Рәмзия САЛИХ

3 – 2001
«Салават күпере» журналына кушымта

Редакция адресы: 420012 Казан шәһәре, Мөштәри урамы, 14нче йорт.
«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм төсләргә бүлендә.

«Идел-пресс» полиграфия нәшрият комплексы» дәүләт унитар предприятиясе
Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Производствога бирелде 9.8.2001 ел. Басарга кул куелды 9.8.2001 ел.
Тиражы 13116 данә. Заказ А-333. Бәясе килешү буенча.